«Сәнгать – авылга» программасы кысаларында А.С.Пушкин исемендәге китапханәнен милли һәм туган якны ойрәнv әдәбияты бvлеге хезмәткәрләре Ромоданово районынын Алтар урта мәктәбендә булдылар. Жиденче сыйныф укучылары очен китапханәчеләр әдәби – агарту дәресләре циклыннан «Мордовиядә туган татар язучылары» дип исемләнгән туган якны ойрәнv сәгате vткәргәннәр. Укучыларыбызга республикабыздан чыккан танылган татар әдәбияты классиклары турында сойләгәннәр.